РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«19» 10 2021 г. № 850

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасы көчләрен булдыру һәм аларны әзерлек хәлендә тоту турында

«Граждан оборонасы турында» 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы турында» 2020 елның 20 февралендәге 10-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Россия Федерациясендә гражданнар оборонасы турында нигезләмәне раслау хакында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2007 елның 26 ноябрендәге 804 номерлы карары, «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Президентының 2008 елның 22 ноябрендәге ПУ-598 номерлы Указы, «Татарстан Республикасы территориясендә гражданнар оборонасы көчләрен булдыру һәм аларны әзерлек хәлендә тоту турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 15 июлендәге 496 номерлы карары нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасы көчләрен һәм чараларын куллануга даими әзерлектә тоту, халыкны хәрби конфликтларда яки бу конфликтлар нәтиҗәсендә килеп чыккан куркынычлардан, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә саклауны тәэмин итү буенча чараларны тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасы көчләре турында Нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасы көчләрен булдырганда оешмалар җитәкчеләренә әлеге карарның 1 пунктында расланган Нигезләмәгә таянып эш итәргә тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җваплылыгымда калдырам.

Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитетының
"____" ___________ 2021 ел
Карары белән  расланды

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасы көчләре турында**

**Гомуми нигезләмәләр**

Әлеге Нигезләмә «Гражданнар оборонасы турында» 1998 елның 12 декабрендәге 28-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы турында» 2020 елның 20 февралендәге 10-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Россия Федерациясендә гражданнар оборонасы турында нигезләмәне раслау хакында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2007 елның 26 ноябрендәге 804 номерлы карары, «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Президентының 2008 елның 22 ноябрендәге ПУ-598 номерлы Указы, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында нигезләмәне раслау турында» Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башлыгының 2020 елның 03 мартындагы №20 карары нигезендә эшләнде һәм Ютазы муниципаль районы территориясендә (алга таба – Ютазы муниципаль районы) гражданнар оборонасы көчләренең составын, төп бурычларын, аларны булдыру, куллану тәртибен, шулай ук әзерлек халәтендә тоту тәртибен билгели.

**1. Граждан оборонасы көчләре**

Ютазы муниципаль районы территориясендә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән түбәндәге гражданнар оборонасы көчләре төзелә:

коткару хезмәтләре;

гражданнар оборонасы буенча чаралар үтәлешен тәэмин итүгә җәлеп ителгән оешмаларның көче һәм чаралары.

**2. Гражданнар оборонасы көчләренең төп бурычлары**

Гражданнар оборонасы көчләренең төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:
коткару хезмәтләре өчен:

- гражданнар оборонасы чараларын үтәүне тәэмин итү буенча махсус чаралар башкару;
- хәрби конфликтлар вакытында яисә шушы конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә халык өчен куркыныч барлыкка килгән очракта авария-коткару һәм башка кичектергесез эшләр башкаруны тәэмин итү;

- хәрби конфликтлар вакытында яисә шушы конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә зыян күргән халыкны беренче чиратта тормыш белән тәэмин итү;
- гражданнар оборонасы өлкәсендәге башка махсус чаралар;
- гражданнар оборонасы буенча чараларның үтәлешен тәэмин итү буенча штаттан тыш формированиеләр өчен - гражданнар оборонасы буенча чараларның үтәлешен тәэмин итүдә һәм гадәттән тыш хәлләрне бетерүдә кичектергесез эшләр башкаруда катнашу.

## 3. Гражданнар оборонасы көчләрен булдыру тәртибе

Гражданнар оборонасы көчләрен булдыру тәртибе: коткару хезмәтләре өчен - «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында Нигезләмәне раслау хакында» 2008 елның 22 ноябрендәге ПУ-598 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы белән билгеләнә;
гражданнар оборонасы буенча чараларны үтәүне тәэмин итүгә җәлеп ителә торган оешмалар көчләре һәм чаралары өчен - Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының 18.12.2014 ел, № 701 боерыгы белән расланган гражданнар оборонасы буенча чараларны үтәүне тәэмин итү буенча штаттан тыш формированиеләр төзүнең Типлаштырылган тәртибе белән билгеләнә.

## 4. Граждан оборонасы көчләрен куллану

4.1. Ютазы муниципаль районы гражданнар оборонасы җитәкчесе карары нигезендә гражданнар оборонасы буенча чаралар үткәрү буенча гражданнар оборонасы көчләрен куллану Ютазы муниципаль районының гражданнар оборонасы һәм халыкны яклау планы нигезендә гамәлгә ашырыла.
Тыныч вакытта гражданнар оборонасы көчләре табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү чараларында катнашу өчен җәлеп ителергә мөмкин.
Гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен тыныч вакытта гражданнар оборонасы көчләрен һәм чараларын җәлеп итү турындагы карарны, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү планына ярашлы, Ютазы муниципаль районы гражданнар оборонасы Җитәкчесе кабул итә.
4.2. Гражданнар оборонасы көчләрен куллануны планлаштыру аларны булдыру этабында алдан ук гамәлгә ашырыла.

## 5. Гражданнар оборонасы көчләрен әзерлек хәлендә тоту

5.1. Гражданнар оборонасы көчләрен әзерлек хәлендә тоту түбәндәгеләр нигезендә тәэмин ителә:
- әлеге Нигезләмәнең 3 бүлегендә билгеләнгән бурычларны үтәүне тәэмин итә торган дәрәҗәдә шәхси составны әзерләү;
- махсус техниканы, җиһазларны, кирәк- яракларны, инструментларны һәм материалларны төзек хәлдә тоту;
- шөгыльләнүләрне һәм оператив әзерлек чараларын планлаштыру һәм үткәрү (тренировкалар, өйрәнүләр).
5.2. Гражданнар оборонасы көчләренең шәхси составын әзерләү Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының закон чыгару һәм башка норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының

идарә органнарын, гражданнар оборонасы көчләрен һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтүнең һәм бетерүнең бердәм дәүләт системасын әзерләү, шулай ук Россия Федерациясе халкын гражданнар оборонасы өлкәсендә гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү, гражданнар оборонасы көчләрен булдыручы оешмалар документлары буенча оештыру-методик күрсәтмәләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

5.3. Гражданнар оборонасы көчләренең торышын күзәтү гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү планына ярашлы рәвештә түбәндәгеләр барышында гамәлгә ашырыла:

- Ютазы муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм оешмалары белән команда-штаб өйрәнүләре һәм тренировкалары;

-Ютазы муниципаль районының гражданнар оборонасы чараларын үтәүне тәэмин итү буенча штаттан тыш территориаль формированиеләр белән тактик-махсус өйрәнүләре;

-Ютазы муниципаль районының коткару хезмәтләре белән махсус өйрәнүләре.

**6. Граждан оборонасы көчләренең эшчәнлеген тәэмин итү**

6.1. Ютазы муниципаль районы гражданнар оборонасы көчләрен булдыру, әзерләү, җиһазлау һәм куллану чараларын финанслау, «Гражданнар оборонасы турында» 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы нигезләмәләрен исәпкә алып, аларны булдыручы оешмаларның финанс чаралары хисабына гамәлгә ашырыла.

6.2. Ютазы муниципаль районы территориясендә төзелә торган гражданнар оборонасы көчләрен җиһазлау өчен билгеләнгән матди-техник, азык-төлек, медицина һәм башка чараларны туплау, саклау һәм алардан файдалану «Гражданнар оборонасы турында» 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы Федераль законда, «Гражданнар оборонасы турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 елның 27 апрелендәге 379 номерлы карары, «Гражданнар оборонасы максатларында матди-техник, азык-төлек, медицина һәм башка чаралар запасларын туплау, саклау һәм алардан файдалану турында» 2014 елның 06 февралендәге 65 номерлы карары, «Татарстан Республикасында матди-техник, азык-төлек, медицина һәм гражданнар оборонасы максатларында башка чаралар запасларын булдыру турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 06 февралендәге 65 номерлы карары белән билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.